

# *Минем нәсел шәҗәрәм*

Төзеде Мифтаахова Г. И.
Түбән Кама шәһәре

# Эшемнең максатлары

**1.Гаилә архивындагы документларны, фотосүрәтләрне, хатларны, иске кульъязмаларны өйрәнү.**

**2.Нәсел агачын – шәҗәрәмне төзү.**

**3.Нәселебезгә караган шәхесләр турында материал туплау.**

**4.Барлык туганнарны әлеге изге эшкә тарту.**

**5.Доклад һәм презентация әзерләү.**

**“Әгәр без борынгы бабаларыбызны онытсак,берникадәр вакыттан соң безне дә онытырлар”(Ш. Мәржани)**





Шәҗәрә - нәсел агачы, бабаларыңның әллә ничә буынга кадәр исемнәрен, дөньядан үтү тәртипләрен белү дигән сүз.

Татар халкында борынгыдан туган тумача, кардәш-ыруга карата кайгыртучан мөнәсәбәт, туып үскән җиренә тирән мөхәббәт яшәгән. Матур тормышта яшәү үрнәген әллә кайдан-читтән эзлисе юк.Ул безнең аяклы тарихыбыз булган әби-бабаларыбызда.Аларның мирасын, тәрбиясен буыннан-буынга тапшыру безнең бурыч,киләчәккә күз төбәп яшәргә кирәк. Шәҗәрә төзү халкыбызның иң матур гадәтләренең берсе.Адәм баласына үзенең 7 буын бабасын белү фарыз,дигәннәр борынгылар.Шул вакытта гына кеше туган иленең,туган төбәгенең,туган йортының,үз халкының чыгышын белә.Без һәрвакыт үткәнебез,кайсы тамырдан булуыбыз белән кызыксынып торырга тиеш.Кем без,нәселебез кая барып тоташа?

Гаилә-җәмгыятьнең иң кечкенә һәм шул ук вакытта иң кирәкле бер күзәнәге.Гаилә,нигездә өч буынны эченә ала:әби-баба,ата-ана,бала-чага.Һәр гаиләнең үз тарихыбар,һәр чәчәк,һәр үлән үзенчә үскән кебек,гаилә дә фәкать үзенчә тамыр җәя,үсә, ныгый.Гаилә башы итеп иң өлкән,физик һәм психик яктан сәламәт,холкы белән камил,ир затыннан булган гаилә әгъзасы саналган.Гаилә шәҗәрәсен алып бару,шәҗәрәне төзү,тикшерү миндә дә кызыксыну уятты.Халкыбызның бер мәкале бар:” Җиде буын бабасын белгән,бәхетле булыр,”-дигәннәр.Шуңа күрә яшьтән үк һәр бала үз нәсел-ыруының кимендә 7 буынын белергә тиеш булган. Зурлар 7 бабаның исемнәрен догаларында искә алганнар.

# Борһановларның нәсел шәҗәрәсе



# Эшем буенча нәтиҗәләр

1.Мин үземнең гаилә шәҗәрәсен төзегәндә шуны аңладым: әби-бабаларны өйрәнгәндә кеше туган иленең, туган төбәгенең, туган йортының, үз халкының чыгышын белә, татар милләте тарихы белән якыннан таныша.

2.Мин үземнең әтием ягыннан гаиләмнең шәҗәрәсен төзедем.

Бу эшемдә миңа төп ярдәмче авылдашыбыз Илфак Шиһаповның “Иске Иштирәк авылы тарихы” китабы булды. Аңа чиксез рәхмәтемне белдерәм.

